| УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ |
|---|---|---|

ПРИКАЗ
«01» декабря 2014 г.

БОЕРЫК
№ 01-05/262 - пр

Казан шәһәре

«Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе тарафыннан җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү комиссиясе турында»

«Дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге № 294-ФЗ Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан контроль чараларын уздыруга җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 10 июлендәге № 636 карары нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

Кемнеке булуына карамастан, тракторларның, үзйөрешле юл-төзелеш һәм бүтән машиналарның һәм аларга тагылмаларның техник торышына тормыш, сәламәтлек һәм мөлкәт өчен иминлек тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне саклау өлешендә; агросәнәгать комплексында машиналарны һәм җайланмаларны, аларга тагылмаларны (Россия Федерациясе Хәрби Көчләре һәм башка гаскәрләре машиналарыннан, шулай ук Федераль экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге хезмәте (Ростехнадзор) контролендә булган машиналар параметрларыннан гайре) файдалану барышында эксплуатацияләү буенча стандартлар, норматив документлар белән

регламентлана торган кагыйдәләрне үтәүгәдәүләт күзәтчелеге чаралары (алга таба – дәүләт күзәтчелеге чаралары) уздыруга Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе тарафыннан җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү, квалификация имтиханнары кабул итү, экспертларның реестрын алып бару комиссиясе турында нигезләмә, әлеге боерыкка 1 нче кушымта нигезендә;

Кемнеке булуына карамастан, тракторларның, үзйөрешле юл-төзелеш һәм бүтән машиналарның һәм аларга тагылмаларның техник торышына тормыш, сәламәтлек һәм мөлкәт өчен иминлек тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне саклау өлешендә; агросәнәгать комплексында машиналарны һәм җайланмаларны, аларга тагылмаларны (Россия Федерациясе Хәрби көчләре һәм башка гаскәрләре машиналарыннан, шулай ук Федераль экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге хезмәте (Ростехнадзор) контролендә булган машиналар параметрларыннан гайре) файдалану барышында эксплуатацияләү буенча стандартлар, норматив документлар белән регламентлана торган кагыйдәләрне үтәүгә дәүләт күзәтчелеге чаралары уздыруга Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе тарафыннан җәлеп ителә торган экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре, әлеге боерыкка 2 нче кушымта нигезендә;

Дәүләт контролен (күзәтчелеген) башкарганда уздырыла торган экспертизалар исемлеге, әлеге боерыкка 3 нче кушымта нигезендә.

2. Күзәтчелек һәм автоматлаштырылган исәпкә алу бүлеге (Р.Ф.Хәйруллин) әлеге боерыкны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә тиеш.

3. Теркәү, автоматлаштырылган исәпкә алу һәм махсус эш секторы (М.Ш.Аймалетдинов) әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе сайтында «Идарәнең эчке документлары» бүлегендә урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының хокукый мәгълүмат рәсми сайтында (PRAVO. TATARSTAN.RU) рәсми бастырып чыгаруны тәэмин итәргә тиеш.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны башлык урынбасары М.А.Халиковка йөкләргә.

Башлык Р.Р.Зыятдинов

Татарстан Республикасы
Үзйөрешле машиналарны һәм
башка төр техниканың техник
торышына күзәтчелек идарәсенең
2014 елның 1 декабрендәге
№ 01-05/262-пр
боерыгына
1 нче кушымта

Кемнеке булуына карамастан, тракторларның, үзйөрешле юл-төзелеш һәм бүтән машиналарның һәм аларга тагылмаларның техник торышына тормыш, сәламәтлек һәм мөлкәт өчен иминлек тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне саклау өлешендә; агросәнәгать комплексында машиналарны һәм җайланмаларны, аларга тагылмаларны (Россия Федерациясе Хәрби Көчләре һәм башка гаскәрләре машиналарыннан, шулай ук Федераль экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге хезмәте (Ростехнадзор) контролендә булган машиналар параметрларыннан гайре) файдалану барышында эксплуатацияләү буенча стандартлар, норматив документлар белән регламентлана торган кагыйдәләрне үтәүгә дәүләт күзәтчелеге чаралары уздыруга Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе тарафыннан җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү, квалификация имтиханнары кабул итү, экспертларның реестрын алып бару комиссиясе турында

## НИГЕЗЛӘМӘ

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе тарафыннан дәүләт күзәтчелеге чаралары уздырганда җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү комиссиясе (алга таба – Комиссия, Идарә) дәүләт күзәтчелеге чаралары уздырганда экспертларны аттестацияләү өчен «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге № 294-ФЗ Федераль закон нигезендә түбәндәге төр экспертизалар буенча төзелә:

инженер-техник һәм технологик экспертиза;

документларга техник экспертиза.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан контроль чараларын уздыруга җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 10 июлендәге № 636 карарына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

## 2. Комиссия вәкаләтләре

2.1. Комиссия түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

дәүләт күзәтчелеге чаралары уздырганда җәлеп ителүче эксперт статусы алуга дәгъва кылучы физик затлар гаризаларын һәм документларын карау;

эксперт статусы алуга дәгъва кылучы физик затларның (алга таба – дәгъва кылучы) квалификацияләрен тикшерү;

дәүләт күзәтчелеге чаралары уздырганда эксперт сыйфатында дәгъва кылучыны аттестацияләү турында карарлар кабул итү.

2.2. Комиссия үзенең составын, Комиссия эше һәм аның каралар кабул итү тәртибен үзгәртү турында Комиссия рәисенә раслау өчен тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

2.3. Комиссия кабул ителгән карарларының нигезлелеге һәм объективлыгы өчен җаваплы.

## 3. Комиссия составы һәм эш тәртибе

3.1. Комиссия Идарә тарафыннан җиде кеше составында төзелә.

3.2. Комиссия составы Идарә башлыгы боерыгы белән раслана. Комиссия составына Комиссия рәисе, Комиссия секретаре һәм Комиссиянең биш әгъзасы кертелә.

3.3. Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә, утырышларда рәислек итә, Комиссия эшен оештыра, Комиссия тавыш биргәндә хәлиткеч тавыш хокукы белән катнаша, Комиссия каралары беркетмәләрен имзалый.

3.4. Комиссия секретаре Комиссиянең эшләрен алып бара, Комиссия утырышында көн тәртибе буенча нотык тота, Комиссия карарлары беркетмәләрен рәсмиләштерә.

3.5. Комиссия үз вәкаләтләрен иҗтимагый башлангычларда башкара.

3.6. Комиссия эшенең төп рәвеше утырышлар була, аларда түбәндәгеләр башкарыла:

гариза бирүче тапшырган документларны һәм белешмәләрне карау;

аттестацияләүдән баш тарту йә гариза бирүчене квалификация имтиханына кертү турында карар кабул итү;

квалификация имтиханы уздыру.

3.7. Комиссия гаризалар (алар булса) кергән көннән 30 көнлек срокта утырыш уздыра. Гариза формасы әлеге Нигезләмәгә кушымтада билгеләнгән.

3.8. Квалификация имтиханы аттестацияләү турында гариза алган көннән өч айдан да соңга калмыйча уздырыла.

3.9. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән, Комиссия утырышында катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия үз компетенциясенә караган мәсьәләләрне хәл итү буенча тулы

хокуклы, әгәр утырышта аның әгъзаларының кимендә яртысы катнашса. Тавышлар тигез булганда, Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч була.

3.10. Комиссия карары беркетмә белән рәмиләштерелә. Комиссия беркетмәсенә Комиссиянең утырышта булган әгъзалары имза сала һәм Комиссия утырышы уздырган көнне Комиссия рәисе тарафыннан раслана.

## 4. Аттестация критерийлары

4.1. Дәүләт күзәтчелеге чаралары уздырганда җәлеп ителә торган эксперт аттестациясе алуга гариза бирүче түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш.

4.2. Гариза бирүченең:

а) югары белеме булырга тиеш;

б) үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы эксплуатацияләү, билгеләү һәм бәяләү буенча кимендә 5 ел эш стажы булырга тиеш;

в) инженер-техник һәм технологик экспертиза, шулай ук документларга техник экспертиза уздыру тәҗрибәсе һәм һөнәри күнекмәләре булырга тиеш.

4.3. Экспертларны аттестацияләү индивидуаль эшкуар булмаган гражданнарга карата уздырыла.

4.4. Гариза бирүче игълан ителгән экспертизалар төрләре өлкәсендәге законнарны белергә тиеш.

4.5. Гариза бирүче үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышы өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы оешмаларның һәм учреждениеләрнең гамәлгә куючысы, директоры, вазыйфаи заты булмаска тиеш.

## 5. Квалификация имтиханы уздыру тәртибе

5.1. Аттестация узу өчен гариза бирүче Идарәгә түбәндәге документларны тапшыра:

а) әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендәге форма буенча гариза;

б) югары белеме турында дипломының күчермәсе;

в) паспорты йә шәхесен таныклаучы бүтән документы күчермәсе;

г) хезмәт кенәгәсе күчермәсе яисә эш стажы булуын раслый торган бүтән документлары;

д) өстәмә белем алуын раслаучы бүтән документлары күчермәләре.

5.2. Квалификация имтиханын уздыру датасы аттестация турында гариза алынган көннән 3 көннән дә соңга калмыйча билгеләнә.

Квалификация имтиханын уздыру датасы Идарәнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында квалификация имтиханын уздыру датасы билгеләнгәннән соң эш көннәрендә исәпләнүче ун көнлек срокта урнаштырыла.

5.3. Дәгъвачының белемнәрен тикшерү үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышы өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча актлар нигезендә уздырыла.

5.4. Граждан тапшырган документларны һәм белешмәләрне тикшерү нәтиҗәләре буенча Идарә тарафыннан түбәндәге карарларның берәрсе кабул ителә:

а) гражданинның аттестациядән баш тартуы турында – гариза бирүче тапшырган документларның әлеге Нигезләмәнең 5.1 пункты таләпләренә һәм (яисә) гражданның аттестация критерийларына туры килмәү очрагында;

б) гражданинны квалификация имтиханына кертү турында.

5.5. Комиссия гражданинга әлеге Нигезләмәнең 5.4 пунктында күрсәтелгән карар кабул итү турында мондый карар кабул ителгәннән соң 5 эш көне эчендә, тапшырылуы турындагы хәбәрнамәсе белән, заказлы почта аша йә гади электрон имза салынган электрон документ рәвешендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша хәбәр итә.

5.6. Квалификация имтиханына әлеге Нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән барлык кирәкле документларны тапшырган һәм әлеге Нигезләмәнең 4 бүлегендә күрсәтелгән аттестация критерийларына туры килүче гражданнар кертелә.

Аттестация турындагы гариза һәм аңа кушып бирелүче документлар күчермәләре гариза бирүче тарафыннан Идарәгә шәхсән яисә, тапшырылуы турындагы хәбәрнамәсе белән, заказлы почта аша йә гади электрон имза салынган электрон документ рәвешендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша җибәрелә.

5.7. Квалификация имтиханы әңгәмә рәвешендә уздырыла. Карау нәтиҗәләре буенча Комиссия дәгъвачының әлеге Нигезләмәнең 4 бүлегендә күрсәтелгән аттестация критерийларына туры килүе йә туры килмәве турында нигезләнгән карар кабул итә.

5.8. Аттестация йомгаклары буенча мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Идарәнең рәсми сайтында Комиссия әгъзалары карар кабул иткән көннән соң өч көнлек срок эчендә урнаштырылырга тиеш.

5.9. Квалификация имтиханы нәтиҗәсе беркетмә белән рәсмиләштерелә, аның нигезендә Комиссия секретаре, әгәр карар аның аттестация критерийларына туры килүе турында йә аттестациядән баш тарту турында кабул ителгән булса, дәгъвачының аттестация критерийларына туры килмәве турында йә аның квалификация имтиханына килмәве турында карар кабул ителгән булса, дәгъвачыны аттестацияләү турында Идарәнең карары проектын әзерли.

Идарә боерыгының күчермәсе карар кабул ителгән көннән 3 эш көне эчендә гариза бирүчегә тапшырыла йә, тапшырылуы турындагы хәбәрнамәсе белән, заказлы почта аша йә гади электрон имза салынган электрон документ рәвешендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша җибәрелә.

5.10. Экспертлар турындагы белешмәләр Идарәнең дәүләт күзәтчелеге гамәлләрен уздырганда җәлеп ителә торган экспертлар реестрына кертелә.

Татарстан Республикасы
Үзйөрешле машиналарны һәм
башка төр техниканың техник
торышына күзәтчелек идарәсенең
2014 елның 1 декабрендәге
№ 01 05/262-пр
боерыгы белән расланган
Нигезләмәгә кушымта

«Татарстан Республикасы Үзйөрешле
машиналарны һәм башка төр техниканың
техник торышына күзәтчелек идарәсе
башлыгына

Экспертны аттестацияләү турында
гариза

Мин, ______________________________________________,
(гариза бирүченең Ф. Ис. Ат. ис.)

мине

______________________________________________
экспертизасы өлкәсендә, (экспертизалар төрләре)
дәүләт күзәтчелеге гамәлләре уздырганда җәлеп ителә торган Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе эксперты аттестациясе алуга квалификация имтиханы узуга кертүегезне үтенәм.

Үзем турында түбәндәгеләрне хәбәр итәм:

Яшәү урынымның адресы ______________________________
Шәхесемне раслаучы документ күрсәткечләре ____________________
______________________________________________
(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
Телефон номеры ______________________________
Электрон почта адресы ______________________________
Почта адресы ______________________________
ИНН ______________________________
Шәхси белешмәләремне эшкәртүгә риза ____________________
(имза)
Документлар кушып бирелә: ______________________________
(документларны барлау)

____________________ ____________________
(дата) (имза)»

Татарстан Республикасы
Үзйөрешле машиналарны
һәм башка төр техниканың
техник торышына күзәтчелек
идарәсенең 2014 елның 01 декабрендәге
№ 01-05/262-пр
боерыгына
2 нче кушымта

Кемнеке булуына карамастан, тракторларның, үзйөрешле юл-төзелеш һәм бүтән машиналарның һәм аларга тагылмаларның техник торышына тормыш, сәламәтлек һәм мөлкәт өчен иминлек тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне саклау өлешендә; агросәнәгать комплексында машиналарны һәм җайланмаларны, аларга тагылмаларны (Россия Федерациясе Хәрби көчләре һәм башка гаскәрләре машиналарыннан, шулай ук Федераль экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге хезмәте (Ростехнадзор) контролендә булган машиналар параметрларыннан гайре) файдалану барышында эксплуатацияләү буенча стандартлар, норматив документлар белән регламентлана торган кагыйдәләрне үтәүгә дәүләт күзәтчелеге чаралары уздыруга Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе тарафыннан җәлеп ителә торган экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару

# КАГЫЙДӘЛӘРЕ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Кагыйдәләр Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең (алга таба – Идарә) дәүләт күзәтчелеге чаралары уздырганда җәлеп ителә торган экспертлары реестрын (алга таба – Реестр) формалаштыру һәм алып бару тәртибен, шул исәптән Реестрга кертелүче белешмәләр составын һәм Реестрдан белешмәләр бирү тәртибен билгели.

2. Реестрны формалаштыруны һәм алып баруны тәэмин итү Идарәнең күзәтчелек бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Реестрда Идарәнең дәүләт күзәтчелеге чаралары уздырганда җәлеп ителә торган экспертлары турында белешмәләр була.

## II. Экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибе

4. Реестрда түбәндәге белешмәләр була:

а) язманың теркәү номеры;

б) эксперт турындагы белешмәләрне Реестрга кертү датасы;

в) физик затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта), яшәү урынының адресы, шәхесен раслаучы документ күрсәткечләре, телефон

номеры һәм электрон почтасы адресы (булган очракта), салым түләүченең идентификацион номеры;

г) аттестация турындагы карар номеры һәм аны кабул итү датасы;

д) яңадан аттестацияләү турындагы карар номеры һәм аны кабул итү датасы;

е) уздырыла торган экспертизалар төрләре;

ж) экспертны аттестацияләү гамәлләрен туктату турындагы карар номеры һәм аны кабул итү датасы; ;

з) экспертның квалификациясе турындагы белешмәләр, шул исәптән квалификация күтәрү, һөнәри әзерлек узу турындагы;

и) экспертның белеме, эш тәҗрибәсе турындагы белешмәләр;

к) эксперт эшләүче яисә хезмәт күрсәтүләр максатларында ул хезмәттәшлек итә торган оешманың атамасы һәм урнашкан җире.

5. Идарәнең күзәтчелек бүлеге түбәндәге чаралардан соң 3 эш көненнән дә артмаган срокта Реестрга белешмәләр кертүне тәэмин итә:

а) аттестация турында, аттестация гамәлләрен туктату турында карар кабул ителгәнннән соң;

б) Реестр белешмәләренә үзгәрешләр кертелгәннән соң.

6. Реестр формасы:

| № т/с | Исеме | Белешмәләр |
|---|---|---|
| 1 | язманың теркәү номеры | |
| 2 | эксперт турындагы белешмәләрне Реестрга кертү датасы | |
| 3 | физик затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта) | |
| 4 | яшәү урынының адресы | |
| 5 | шәхесен раслаучы документ күрсәткечләре | |
| 6 | телефон номеры һәм электрон почтасы адресы (булган очракта) | |
| 7 | салым түләүченең идентификацион номеры | |
| 8 | аттестация турындагы карар номеры һәм аны кабул итү датасы | |
| 9 | яңадан аттестацияләү турындагы карар номеры һәм аны кабул итү датасы | |
| 10 | уздырыла торган экспертизалар төрләре (инженер-техник һәм технологик экспертиза; документларга техник экспертиза) | |
| 11 | экспертның квалификациясе турында белешмәләр, шул исәптән квалификация күтәрү, һөнәри әзерлек узу турында һәм белеме, игълан ителгән экспертиза төре буенча эш тәҗрибәсе турындагы белешмәләр | Күрсәтелә: мәгариф учреждениесенең атамасы; белеме турындагы документ номеры һәм аны бирү датасы; бирелгән белгечлек, квалификация атамасы; эксперт эшләгән оешмалар исемлеге, вазыйфасын күрсәтеп |

| | | |
|---|---|---|
| 12 | эксперт гариза бирү мизгеленә эшли торган оешманың атамасы һәм урнашкан җире | |

### III. Реестрдагы белешмәләрне бирү тәртибе

7. Реестрдагы белешмәләр алар белән дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик һәм физик затлар танышу өчен ачык була, моңа Россия Федерациясе законнары нигезендә алуы чикләнгән мәгълүмат дип санала торган белешмәләр керми.

8. Реестрдагы белешмәләрне алу Идарәнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында әлеге белешмәләрне ачык күрсәткечләр рәвешендә урнаштыру юлы белән тәэмин ителә, моңа Россия Федерациясе законнары нигезендә алуы чикләнгән мәгълүмат дип санала торган белешмәләр керми.

9. Реестрдагы белешмәләрне гарызнамәләр буенча бирү тиешле гарызнамә кергән көннән 15 эш көненнән дә артмаган срокта Идарә тарафыннан гамәлгә ашырыла.

10. Реестрдагы белешмәләр түләүсез бирелә.

Татарстан Республикасы
Үзйөрешле машиналарны һәм башка
төр техниканың техник торышына
күзәтчелек идарәсенең 2014 елның
01 декабрендәге
№ 01-05/262-пр
боерыгына
3 нче кушымта

Дәүләт контроле (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда уздырыла торган экспертизалар исемлеге

1. Инженер-техник һәм технологик экспертиза;
2. Документларга техник экспертиза.